Казан шәһәре Яңа Савин районының
19 нчы катнаш төрдәге татар телендә
тәрбия һәм белем бирүче
балалар бакчасының
1 нче педагогик киңәшмә утырышында
кабул ителде 25.08. 2021
Приказ №65-О

“19 нчы катнаш төрдәге
татар телендә тәрбия һәм белем
бирүче балалар бакчасы” мөдире
/ М.А. Воскобойникова

# Муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “19 нчы катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче балалар бакчасы” татар теле тәрбиячесе Закирова Р.Вның 2021-2022 нче уку елына эш программасы

**Казан, 2021 ел**

**ЭЧТӘЛЕК**

I. МАКСАТЧАН БҮЛЕК ........ 4

*1.1. Аңлатма язуы.* ........ 4

1.2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның психик усеше узәнчелекләре ........ 4

*4-5 яшьлек балаларның психик үсеше үзәнчелеге* ........ 4

*5-6 яшьлек балаларның психик үсеше үзәнчелеге* ........ 5

*6-7 яшьлек балаларның психик үсеше үзәнчелеге* ........ 6

*1.3. Программа принциплары.* ........ 6

1.4. Программаның төп максатлары һәм бурычлары ........ 7

1.5. Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар һәм формалар ........ 8

II. ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ ........ 9

2.1. Тематик планнар ........ 9

*“Минем өем” проекты* ........ 9

*“Уйный – уйный үсәбез” проекты* ........ 13

“*Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар*” ........ 20

2.2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның татар телендә сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен тикшерү. ........ 25

Уку елы ахырында уртанчылар,  уку елы башында зурлар төркеме балаларының ........ 25

“Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү. ........ 25

Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез”проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү. ....29
Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының ....30
“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү. ....30
2.3. 2021-2022 нче уку елына эш планнары ....32
*Балалар белән эш планы* ....32
*Тәрбиячеләр белән эш планы* ....33
*Ата-аналар белән эш планы* ....34
III. ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ ....35
3.1. Татар теле тәрбиячесенең ата-аналар белән бердәм эшчәнлеге ....35
3.2. Татар теле тәрбиячесенең белгечләр белән бердәм эшчәнлеге ....36
3.3. Татар теле тәрбиячесенең тәрбиячеләр белән бердәм эшчәнлеге ....36
*3.4* Программаны  методика белән тәэтмин итү ....36

# I. МАКСАТЧАН БҮЛЕК

## *1.1. Аңлатма язуы.*

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус телле балаларны татарчага өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы (алга таба программа) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре”нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары нигезендә расланган) нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына (Л. С. Выготский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, Е. А. Пассов) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

## *1.2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның психик усеше узәнчелекләре*

### *4-5 яшьлек балаларның психик үсеше үзәнчелеге*

Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгән рольдән үзләрен аера башлыйлар.

Сурәтләү эшчәнлеге шактый үсеш ала. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән формаала. Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың уңай үзгәрешләре беләнхарактерлана. Җитезлек, хәрәкәт координациясе үсә. Кечкенәләр белән чагыштырганда балалар бу яшьтә тигезлекне яхшы саклыйлар, зур булмаган тоткарлыкларны атлап чыгалар. Зиһенгә алу сәләте күбрәк үсеш ала. Балалар теге яки бу предметка охшаган форманы атый беләләр, хәтер күләме үсә.

Балалар 7-8 предметың исемен истә калдыра алалар. Тасвирлы фикерләү сәләте үсә башлый. Балалар катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишүдә гади схемалаштырылган сүрәтләр кулланалар. Күз алдына китерү, уйлап чыгару сәләте

үсә. Балалар мөстәкыйль рәвештә бирелгән темага зур булмаган әкият уйлап чыгара алалар. Игътибарлылык сәләте үсә. Бала 15-20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли алырга сәләтле.

Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Бала өлкәннәрнең үзен ихтирам

итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зур әһәмияткә ия була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Артык үпкәләүчәнлек, бу яшьнең феномены булып тора.

Яшьтәшләре белән бала сайлап кына аралаша башлый. Ул кайбер иптәшләренә

өстенлек бирә. Уен вакытында, даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Ярышу үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен детальләштерүгә китерә.

Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү; сурәтләү эшчәнлеге үсү; үзең уйлап конструкторлаштыру; планлаштыру, зиһенгә алу сәләте камилләшү, образлы, хыялый фикерләү, танып-белүдә мин-минлек; көндәшлек ярышу кебек сыйфатлары барлыкка килә.

***5-6 яшьлек балаларның психик үсеше үзәнчелеге***

Алтынчы яшьтәге балалар үзен һәм башкаларны белергә омтыла, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне аңлый башлый. Аларның сүзлекләрендә инде намуслылык, кайгыртучанлык, әдәплелек кебек сүзләр күбрәк урын ала. Балалар уенындагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Аларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрендәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар. Бер төрле рольләр аларны башкалары белән чагыштырганда күбрәк җәлеп итә.

Бу яшьтә уйлап чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның әлеге сәләте бары тик бу юнәлештә махсус эш алып барганда гына актив рәвештә үсәчәк.

Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Алар шулай ук игътибарларын кирәк юнәлешкә бора һәм башкага күчерә ала башлыйлар. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә.

Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Балалар сызгырулы, чыңылдаулы һәм сонор авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Шигырьләр укыганда, сюжетлы-рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте, сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә, грамматик төзелеше камилләшә. Балалар барлык сүз төркемнәрен кулланалар, сүз уйлап чыгару белән актив шөгыльләнәләр. Сүз байлыклары арта. Синоним белән антонимнар актив кулланышка керә.Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар эчтәлекне дә, рәсемнәр буенча да иң мөһим генә түгел, ә детальләрне дә кертеп сөйли ала башлыйлар.

Бу яшьнең казанышлары түбәндәгеләр белән характерлана: уен эшчәнлегендә рольләр бүлешү; уен пространствосын төзи белү; югары нәтиҗәлелеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше;

конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү. Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана; фикерләү чараларын (схемалы, комплекслы күзаллаулар, цикллы үзгәрешләр турында күзаллаулар) үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте дә үсә, гомумиләштерү күнекмәләре, уйлап чыгару сәләте, тотрыклы игътибар, сөйләм, Мин образы үсә.

***6-7 яшьлек балаларның психик үсеше үзәнчелеге***

Бу чорда балалар тормшында яңа этап башлана. Ул дөньяны, кешелек мөнәсәбәтләрен башка яктан өйрәнә. Тормышта үз урынын эзли башлый. Баланың кечкенә генә үз дөньясы барлыкка килә. Без аны микромир дип йөртәбез. Ул анда яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән хезмәттәшлек итәргә өйрәнә. Аңа мәктәп куйган яңа кагыйдәләргә, таләпләргә буйсынырга туры килә. Бала әкренләп социаль тирәлеккә ияләшә.Өлкәннәр һәм сыйныфташлары белән аралашканда үз позициясен билгели һәм алар белән хезмәттәшлек итә башлый.

Әйләнә-тирәне үз күзлегеннән чыгып өйрәнә, нәтиҗә ясый. 7 яшеннән бала бар нәрсәне башка күзлектән карый, аңлый һәм үз бәясен бирә.

Мәсәлән, бала өчен кечкенә таш җиңел әйбер. Ә мәктәптә ул ташның судан авыррак икәнлеген күзәтә, чөнки ул суда бата. Һәм башка шундый мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Уен формалары белән бергә кызыксыну,уйлау эшчәнлеге кушыла. Ләкин балага уеннан укуга күчү бик авыр бирелә.Шуңа күрә ул тиз арый, көйсезләнә башлый.

***1.3. Программа принциплары.***

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

*Интеграция һәм дифференциация принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:* аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

*Белем бирүне комплекслы-тематик принципка корып оештыру;*

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау,

кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы* - гадидән катлаулыга таба бару.

*Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

## *1.4. Программаның төп максатлары һәм бурычлары*

**Татарча сөйләшергә өйрәткәндә куелган минимум бурычлар.**

Программа өч проектны һәм аларның төп максатларын һәм бурычларын үз эченә ала:

**“Минем өем” проекты (4-5 яшь).**

Максат: Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.

2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.

3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты (5-6 яшь).**

Максат: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.

2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.

3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь).**

Максат: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар:1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

### *1.5. Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар һәм формалар*

**Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.**

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлегe өчен материаллар.
4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

**Эш төрләре һәм формалары.**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## II. ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ

### *2.1. Тематик планнар*

**Укыту методик комплектының эчтәлеге.**
Һәр проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар һәм әти-әниләр өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоязмалар;
5) анимацион күренешләр;
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

**“Минем өем” проекты. (**4-5яшьлек балалар өчен)
**Лексик минимум** – якынча 62 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.
**Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз)
**Сөйләм үрнәкләре:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)
**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- гаилә
- ашамлыклар
- уенчыклар
- саннар

Атна дәвамында 20 шәр минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

**Тематик план.**

| Актив сузләр | Сөйләм урнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм |
|---|---|---|

| Гаилә – 18  сәгать (1-18) | | |
|---|---|---|
| әти<br>әни<br><br>малай<br>кыз<br><br>мин<br>исәнмесез<br>сау булыгыз<br><br><br><br>исәнме<br><br><br>эт<br>песи<br><br><br><br><br>әйе<br>юк<br>сау бул<br><br><br>әби<br>бабай | -Бу кем?<br>-Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем юк?<br>-Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).<br><br>-Исәнмесез.<br>-Син кем?<br>-Мин Коля (Оля).<br>-Мин малай.<br>-Сау булыгыз!<br><br>-Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>-Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем анда?<br>-Мин песи. Мин Мияу.<br>-Кил монда.<br>-Мин эт. Мин Акбай.<br>-Кил монда.<br><br>-Син Коля?<br>-Әйе, Коля.<br>-Син малай (кыз)?<br>-Әйе (юк).<br><br>-Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Әйе.<br>-Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Юк.<br><br>-Малай?<br>-Юк, кыз.<br>-Кыз?<br>-Әйе, кыз. | Аудиоязма №1-23<br><br>Дәфтәрдә эш №1-4<br><br><br><br>Мультфильмнар:<br>1. “Әйдәгез, дуслашыйк”<br>2. “Качышлы уйныйбыз”<br>3. “Шалкан” |

| | | |
|---|---|---|
| әйбәт | -Хәлләр ничек?<br>-Әйбәт. | |
| **Ашамлыклар – 12 сәгать (19-30)** | | |
| ипи<br>мә<br>рәхмәт | -Мә, ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт, әби. | Аудиоязма №24-39 |
| алма<br>сөт<br>чәй | -Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт. | Дәфтәрдә эш №5-10<br>Мультфильмнар:<br>1.“Тәмле” кибетендә”<br>2. “Азат кунак чакыра” |
| тәмле<br>кил монда<br>утыр | -Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля)<br><br>-Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>-Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт.<br><br>-Мә, тәмле алма (ипи). | |
| аша<br>эч | -Мә, ипи (алма) аша.<br>-Мә, сөт  (чәй) эч. | |
| **Уенчыклар – 18 сәгать (31-48)** | | |
| туп | - Бу нәрсә?<br>- Туп (курчак, куян, аю). | Аудиоязма №40-53 |
| бир | -Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>-Мә, курчак (туп, куян, аю). | Дәфтәрдә эш №11-13 |
| зур<br>кечкенә | -Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>-Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт). | Мультфильмнар:<br>1. “Паркка сәяхәт”<br>2. “Уенчыклар үпкәләгән”<br>3. “Күңелле уеннар”<br>4. “Акбай һәм Мияу маҗаралары” |
| матур | - Аю (курчак, куян, туп) нинди? | |

| | | |
|---|---|---|
| курчак | - Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт). | |
| куян<br>аю<br>уйна | -Аю (курчак, куян, туп)?<br>-Әйе.<br>-Курчак (аю, куян, туп)?<br>-Юк. | |
| | -Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна. | |
| | -Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна. | |
| | - Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә. | |
| ю | - Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна). | |
| | -Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю. | |
| хәлләр ничек? | - Исәнме, Мияу!<br>- Исәнме, Акбай!<br>- Хәлләр ничек?<br>- Әйбәт. | |
| пычрак<br>чиста | -Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю.<br>-Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак.<br>(Әйе, туп чиста). | |

| | | |
|---|---|---|
| | Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| **Саннар - 6 сәгать (49-54)** | | |
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br><br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Мультфильм:<br>1.“Уйный-уйный саныйбыз” |
| **Кабатлау - 6 сәгать (55-60)** | | |
| | | Аудиоязма №25<br>Дәфтәрдә эш №61-64<br>Мультфильм:<br>1. “Күңелле ял итәбез” |

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты. (**5-6 яшьлек балалар өчен)

**Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)

**Сөйләм үрнәкләре:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз).

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- яшелчәләр
- ашамлыклар
- савыт- саба

- киемнәр
- шәхси гигиена
- өй җиһазлары
- бәйрәм “Туган көн”
- бәйрәм “Сабан туй”
- Уртанчылар төркемендәге темалар(гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

Атнага 25 шәр минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

**Тематик план.**

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм** |
|---|---|---|
| | **Кабатлау – 3 сәгать (1-3)** | |
| | “Минем өем” проекты буенча | Аудиоязма №1<br><br>Дәфтәрдә эш №1<br><br>Мультфильм:<br>1. “Шалкан” |
| | **Яшелчәләр – 21 сәгать (4-24)** | |
| кишер<br><br><br><br>баллы<br><br>ничә<br><br>суган<br>бәрәңге<br><br>кыяр | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә, кишер.<br><br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Рәхмәт.<br><br>-Зур кишер (суган, бәрәңге, | Аудиоязма №2-24<br><br>Дәфтәрдә эш №2-6<br><br>Мультфильмнар:<br>1.“Баллы кишер”<br>2. “Уйный-уйный эшлибез”<br>3. “Юл маҗаралары”<br>4. “Кем эшләми, шул ашамый” |

| | | |
|---|---|---|
| кәбестә<br>нинди<br><br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз<br>ун | кәбестә, кыяр)<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак)<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>-Мә кишер(алма), аша. Баллы?<br>-Әйе, баллы. Рәхмәт.<br><br>-Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Коля, (1-10) кәбестә (суган, | |

| | | |
|---|---|---|
| кызыл<br>сары<br><br>яшел<br><br>нәрсә кирәк?<br><br>юа | бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>-Сау бул, Коля.<br><br>-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>-Бу туп.<br>-Туп (алма) нинди?<br>-Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>-Нинди туп (алма) юк?<br>-Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>-Кирәк.<br><br>-Коля, нәрсә кирәк?<br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>-Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br><br>-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, | |

| | | |
|---|---|---|
| | кәбестә) юа. | |
| **Ашамлыклар – 6 сәгать (25-30)** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Аудиоязма №25-29<br><br>Дәфтәрдә эш №7, 8<br><br>Мультфильм:<br>1.“Аш бүлмәсе” |
| **Савыт-саба - 6 сәгать (31-36)** | | |
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | -Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Мультфильм:<br>1. “Өч аю”<br>2. “Чисталыкта - матурлык” |
| **Киемнәр - 6 сәгать (37-42)** | | |
| күлмәк | яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк | Аудиоязма №38-43 |

| | | |
|---|---|---|
| чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br><br>сал<br><br><br><br><br><br>йокла | (чалбар).<br><br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br><br>күлмәк (чалбар) юк.<br><br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>-Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br><br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Курчак, йокла. | Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Мультфильм:<br>1.“Киемнәр кибетендә”<br>2.“Шаян уенчыклар” |
| **Шәхси гигиена – 3 сәгать (43-45)** | | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br>-Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44-48<br><br>Эш дәфтәре №13, 14<br><br>Мультфильм<br>1.“Ни өчен киемнәр югалган?” |
| **Өй җиһазлары – 3 сәгать (46-48)** | | |
| өстәл<br>урындык<br>карават | -Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават).<br><br>-Зур аю, мә зур карават (өстәл, | Аудиоязма № 49<br><br>Эш дәфтәре №15 |

| | | |
|---|---|---|
| | урындык).<br>-Кечкенә аю, мә кечкенә караватۦ (өстәл, урындык).<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Карават (өстәл, урындык) кирәк.<br>-Нинди карават?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) карават.<br>-Мә, зур карават.<br>-Рәхмәт. | Мультфильм:<br>1.“Маша һәм өч аю” |
| **Бәйрәм “туган көн” – 9 сәгать (49-57)** | | |
| яратам<br><br><br><br><br><br><br><br><br>бар | -Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>-Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br><br>-Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>“Бар”, “Юк” сүзләрен кулланып “Гаилә”, “Яшелчә” “Уенчыклар” темаларын кабатлау.<br>Диалогларны кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | Аудиоязма №50-60<br><br>Эш дәфтәре №16-19<br><br>Мультфильм:<br>1. “Туган көн”<br>2. ”Кем нәрсә ярата?” |
| **БӘЙРӘМ “САБАНТУЙ”- 3 СӘГАТЬ (58-60)** | | |
| | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>“Гаилә”, “Яшелчә”, “Уенчыклар” темаларын кабатлау. | Аудиоязма №61-63<br><br>Мультфильм:<br>1.“Сабантуй бәйрәме” |

| | | |
|---|---|---|
| | “Кибетле” уеннары. | |

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.**

6-7 яшьлек балалар (мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен якынча 60 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.

**Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың?(пассив сүз)

Проектның эчтәлеге уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган.

Атнага 30 ар минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

**Тематик план**

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм** |
|---|---|---|
| син кем?<br><br>хәерле көн<br><br><br><br><br><br><br>тычкан<br><br><br>бу кем? | <br><br>-Хәерле көн, Оля (Коля).<br>-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби). | Аудиоязма №1 - 2<br><br>Аудиоязма №3 - 5<br>Дәфтәрдә эш №1<br><br>Мультфильм: “Мияу адашкан”<br><br>Аудиоязма №6<br>Дәфтәрдә эш №2<br><br>Аудиоязма №7 - 8<br>Дәфтәрдә эш №3<br><br>Мультфильм:”Аю баласы дөнья белән таныша”<br><br>Аудиоязма №9 - 10 |

| | | |
|---|---|---|
| | | Дәфтәрдә эш №4 |
| бу нәрсә? | -Песи нишли? | |
| | -Песи йоклый. | Аудиоязма №11 |
| нишли? | -Әни нишли? | |
| йоклый | -Әни утыра. | Мультфильм: “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай” |
| утыра | | |
| | | Аудиоязма №12 |
| | | Дәфтәрдә эш №5 |
| ашый | -Коля нишли? | |
| эчә | -Коля ашый (эчә). | Аудиоязма №13 - 14 |
| нишлисең? | -Мияу, нишлисең? | |
| ашыйм | -Ашыйм. | |
| эчәм | -Акбай, нишлисең? | Мультфильм: |
| | -Эчәм. | “Тату гаилә” |
| | | Аудиоязма №15 |
| уйный | -Оля (Коля), нишлисең? | |
| уйныйм | -Уйныйм. | Аудиоязма №16 - 18 |
| утырам | | Мультфильм: “Юмарт аю” |
| | | Аудиоязма №19 |
| | | Аудиоязма №20 |
| барам | -Кая барасың? | Дәфәрдә эш №6 |
| кая барасың? | -Кафега барам. | |
| син нишлисең? | -Син нишлисең? | |
| | -Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый) | Мультфильм: “Кафега барабыз” |
| | | Дәфтәрдә эш №7 |

| | | |
|---|---|---|
| сикер-сикерәм | Туп, туп<br>Матур туп.<br>Сикер-сикер,<br>Матур туп. | Аудиоязма №21-23 |
| сикерә<br>йөгерә<br>төлке | Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә.<br>Песи сикерә (йөгерә).<br>Төлке сикерә (йөгерә). | Мультфильм:<br>“Урманда күңелле уеннар”<br><br>Аудиоязма №24<br>Дәфтәрдә эш №8<br><br>Аудиоязма №25-28 |
| йөгер-йөгерәм | -Йөгер! Син нишлисең?<br>-Мин йөгерәм. | Мультфильм:<br>“Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” |
| чәк-чәк<br>өчпочмак | -Мин чәк-чәк ашыйм.<br>-Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма №29-30<br>Дәфтәрдә эш №9 |
| яшь | -Сиңа ничә яшь?<br>-6 яшь. | Мультфильм:<br>“Җәнлекләр спорт бәйрәмендә”<br><br>Аудиоязма №31-32 |
| бүре<br>керпе | -Мин бүре. Мин зур, матур, чиста. | Аудиоязма №33-34<br>Дәфтәрдә эш №10 |
| тавык<br>әтәч | Әтәч зур, матур<br>Тавык кечкенә, матур | Мультфильм:<br>“Циркта” |
| үрдәк | -Син кем? | Аудиоязма №35 - 36<br>Дәфтәрдә эш №11 |

| | | |
|---|---|---|
| | -Мин үрдәк. | |
| | | Аудиоязма №37 - 38 |
| | | Дәфтәрдә эш №12 |
| | | Мультфильм: |
| чана | Куян чана шуа. | “Шаян кошлар” |
| шуа | | |
| | | Аудиоязма №39 - 40 |
| шуам | Мин чана шуам. | |
| | | Аудиоязма №41 |
| | | Дәфтәрдә эш №13 |
| | | Мультфильм: |
| бие | -Аю, әйдә, бие! | “Урманда зур концерт” |
| бии | | |
| | | Аудиоязма №42 - 44 |
| биим | | Дәфтәрдә эш №14 |
| | | Аудиоязма №45 - 46 |
| ак | -Оля кызыл шар ярата? | Мультфильм: “Акбай туган көнгә барырга |
| кара | -Юк. | җыена” |
| | -Оля яшел шар ярата? | |
| | -Әйе, мин яшел шар яратам. | Аудиоязма №47 |
| | | Дәфтәрдә эш №15 |
| җырла-җырлыйм | -Син нишлисең? | |
| | -Мин җырлыйм. | Аудиоязма №45, 48 – 49 |
| | | Мультфильм: |
| | | “Мияуның туган көне” |
| | җырлыйбыз | Аудиоязма №50 |
| | зур рәхмәт | Дәфтәрдә эш №16 |

| | | |
|---|---|---|
| зур рәхмәт | | Аудиоязма №51 - 53<br>Дәфтәрдә эш №17<br><br>Мультфильм:<br>“Урман китапханәсендә” |
| китап укый | Кыз китап укый. | Аудиоязма №54 - 60<br>Дәфтәрдә эш №18 |
| рәсем ясыйм | рәсем ясыйм-алма ясыйм<br>мәктәп | Мультфильм “Уйный-уйный укыйбыз”<br><br>Аудиоязма №61-63<br>Дәфтәрдә эш №19 |
| укыйм | -Кем укый.<br>-Мин укыйм. | Мультфильм: “Урман мәктәбендә”<br><br>Аудиоязма №64 |
| дәфтәр | бик тәмле | |
| | Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Алар бик дус. | Мультфильм: “Теремкәй”<br><br>Аудиоязма №65-66 |

| | | |
|---|---|---|
| | -Кәҗә кая?<br>-Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br><br>-Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>-Мә, кәҗә, ботка аша.<br>-Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | Мультфильм: “Кем нәрсә ярата?”<br><br>Аудиоязма №67 - 71<br>Дәфтәрдә эш №20 |

## 2.2. МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ (АРАЛАША) БЕЛҮ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ.

***Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының “Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.***

| № | Баланың исеме, фамилиясе | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |

| | | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.**

1. “**Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

***<u>1. Дидактик уен. "Бу кем?"</u>*** *<u>(I вариант)</u>*

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)

Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).

***2. Дидиктик уен "Кем юк?"** (II вариант)*

(Лексика шул ук).Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)

Уенны интерактив тактада да, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була)

***3. Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"***

(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)

***4. Дидактик уен "Нәрсә юк?"***

Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...) Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.

***5. Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"***

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай; куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).

Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.

***6. Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Тәрбияче өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны(рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?"- "Алма"... ; "Бу кем?"-"Әти"... Бала уенчык исемен дөрес әйтсә аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.

***7. Дидактик уен "Серле янчык"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.

***8. Дидактик уен "Әйе-юк"***

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?" - "Аю"...; "Бу аю?" - "Әйе, аю"...; "Бу куян?" - "Юк, песи"...

**Югары балл (2.7-3)** — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.

**Уртача балл (2-2,6)** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

***Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез”проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.***

| № | Баланың исеме, фамилиясе | **Биремнәр** | | | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |
| | | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля... | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**1.“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

**(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

1. ***Дидактик уен “Бу нәрсә?”***

(Лексика: аш, ботка, сөт, кашык, тәлинкә, чынаяк).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:

- Бу нәрсә? (“Аш”...)

2. ***Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: “Нәрсә бар?” (“Кәбестә”...)

3. ***Дидактик уен “Нәрсә юк?”.***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя: “Нәрсә юк?”. Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***Дидактик уен “Дөресен әйт”.***

(Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, карават).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрнең исемен атый һәм күрсәтә.

**Югары балл (2.7-3)** — сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә һәм куелган сорауларга җавап бирә.

**Уртача балл (2-2,6)** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

***Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының***
***“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.***

| № | Баланың исеме | **Биремнәр** | **Нәтиҗә** |
|---|---|---|---|

| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | **баллар** | **дәрәҗә** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтеле, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, “хәерле көн”,“хәлләр ничек?”, “әйбәт”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, жырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

## *2.3. 2021-2022 нче уку елына эш планнары*

**Балалар белән эш планы**

| № п/п | Эш төрләре | Вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Уртанчылар төркеме балалары белән танышу, төркемнәрдә каршы алу. Эш дәфтәрләре булдыру. | Сентябрь |
| 2. | Көз “Алтын көз”, “Сөмбелә” бәйрәмнәрен үткәрү, җырлар, шигырьләр өйрәнү. | Октябрь-Ноябрь |
| 3. | “Яңа ел” бәйрәменә җырлар, шигырьләр өйрәнү. | Декабрь |
| 4. | “Туган тел” көнен үткәрү. | Февраль |
| 5. | “Әниләр” һәм “Нәүрүз” бәйрәмнәрен әзерләү. Җырлар, шигырьләр өйрәнү. | Март |
| 6. | Габдулла Тукай иҗатына багышланган атналык әзерләү. Шигырь конкурсын үткәрү. | Апрель |
| 7. | Төркемнәрдә балаларның татар, ана телен үзләштерүен тикшерү, анализлау. | Май |
| 8. | “Сабантуй” бәйрәмен үткәрү. | Июнь |

**Тәрбиячеләр белән эш планы**

| № п/п | Эш төрләре | Вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Эш планнары төзү, төркемнәрдәге стендларны яңарту. | Сентябрь |
| 2. | Көз “Алтын көз”, “Сөмбелә” бәйрәмнәрен әзерләүдә ярдәм күрсәтү. Җырлар, шигырьләр өйрәнү.<br>Консультация: “Татар телен кызыксындырып өйрәтү” | Октябрь |
| 3. | Консультация: “Саф һавада УМК ны куллану” | Ноябрь |
| 4. | “Яңа ел” бәйрәменә әдәби-музыкаль репертуар сайлауда һәм үткәрүдә ярдәм итү. Җырлар, шигырьләр өйрәнү.<br>Консультация: “Сүзле уеннар кулланып балаларның сөйләм телен үстерү” | Декабрь |
| 5. | Консультация: “УМК буенча үткән материалны ныгыту төрләре һәм методлары”. | Январь |
| 6. | Ватанны саклаучылар көненә һәм “Туган тел көне” нә багышланган кичәне оештыруда ярдәм күрсәтү.<br>Әдәби-музыкаль кичә “Батыр-шагыйр Муса Җәлил” | Февраль |
| 7. | “Әниләр” һәм “Нәүрүз” бәйрәмнәрен үткәрүдә ярдәм күрсәтү. | Март |
| 8. | Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатына багышланган кичәне әзерләү һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтү. | Апрель |
| 9. | Ачык шөгыльләр күрсәтү | Май |

**Ата-аналар белән эш планы**

| № п/п | Эш төрләре | Вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Төркемнәрдәге ата-аналар җыелышларында чыгыш ясау. | Сентябрь |
| 2. | “И туган тел, и матур тел” стендын яңарту. | Октябрь |
| 3. | “Ышаныч” телефоны. Татар телен өйрәнү буенча ата-аналарның сорауларына җавап бирү. Яшь әти-әниләр мәктәбе. | Ноябрь |
| 4. | Консультация: “Без татар телендә сөйләшәбез”. | Декабрь |
| 5. | “Ачык ишекләр” көне. Шөгыльләр күрсәтү | Январь |
| 6. | “Ышаныч” телефоны. Консультация: “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү”. | Февраль-Март |
| 7. | “И туган тел, и матур тел” стендын яңарту. | Апрель |
| 8. | “Ачык ишекләр” көне. Ата-аналарга шөгыльләр күрсәтү. Ата-аналар җыелышларында катнашу. | Май |

# III. ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ

## 3.1. Татар теле тәрбиячесенең ата-аналар белән бердәм эшчәнлеге

Гаилә - җәмгыятьнең нигезе, аның беренчел оешкан төркеме (коллетивы). Шулай булгач, милләтнең бөтенлеге һәм саулыгы гаилә ныклыгына турыдан-туры бәйле.

Гаилә исламдагы һәм татар халык тәҗрибәсендәге рухи- әхлакый кыйммәтләргә нигезләнеп яшәсә генә тотрыклы була һәм үз вазифаларын (беренче чиратта балалар тәрбиясе) үти ала. Гаилә кешене шундый мохит белән чолгап ала һәм тәэмин итә ки, анда кеше кыйммәтләре һәм әхлагы яңа буында барлыкка килә һәм үсә. Әлеге кыйммәтләр һәм әхлак гаиләдән башка яши алмый. Гаиләдә атмосфера һәм аның әгъзалары арасындагы үзара мөнәсәбәтләр тулысынча җәмгыятьнең характерын, аның үсеш дәрәрҗәсен билгели.

Халыкны милләт буларак саклап калуда, аның рухи - әхлакый халәтен формалаштыруда гаиләнең әһәмияте бик зур. Милли хис-тойгы һәм милли аңның да формалашу урыны – гаилә. әлеге милли тойгы – аң гаиләдәге нәкъ менә тәрбия чаралары булырга тиешле дини – милли әдәбият, туган тел, гореф-гадәтләр, гаилә традицияләре ярдәмендә тамырлана, үсә, шулар нигезендә ныгытыла.

Балаларны гаиләдә намуслы, әдәп-әхлаклы, хезмәт белән гадел көн күрә, фарыз гамәлләрен үтәп, харәм эшләрдән тыелып яши белә торган итеп үстерү – ата-ананың халык, милләт, җәмгыять алдында олы, үтә җаваплы вазифалары. Аның шулай булуын күренекле педагог А.С.Макаренко сүзләре дә раслый. “Балалар - безнең картлыгыбыз, начар тәрбия

- киләчәктәге кайгыбыз, күз яшьләребез, башка кешеләр һәм бөтен ил алдындагы гаебебез", - дип яза ул. Бу сүзләр татар халкындагы бик үзенчәлекле, кисәтүле тәкъбир белән аваздаш: "Баладан бәхетең булса, карт көнеңдә яшь итәр, баладан бәхетең булмаса, иртә яшьтән карт итәр". Димәк, әдәп-әхлаклы, иманлы, акыллы - түәфыйклы балалар үстергән кеше үзе дә тыныч картлык кичерә, андый гаилә милләт, халык бердәмлегенә, аның алгарышына да үзенең лаеклы өлешен кертә.

## 3.2. Татар теле тәрбиячесенең белгечләр белән бердәм эшчәнлеге

1. Музыка җитәкчесе белән бердәм эшчәнлектә әдәби-музыкаль репертуар сайлауга ярдәм итә.
2. Бәйрәм кичәләрен әзерләүдә һәм үткәрүдә катнаша.
3. Логопед белән белән бердәм эшчәнлектә балаларның үзәнчелекләрен, сөйләмдә булган кимчелекләрен ачыклый, аларны төзәтүдә ярдәм итә.
4. Психолог белән бердәм эшчәнлектә баларның психофизик, эмоциональ, индивидуаль узәнчелекләрен күзәтә, үзенең киңәшләрен бирә.
5. Физик тәрбия инструкторы белән бердәм эшчәнлектә балаларның физик үсешенә йогынты ясый, ярдәм итә.
6. Белгечләр белән бердәмлектә татар халыкның милли уеннарын, җырларын балаларга җиткерү өстендә эш алып бара.
7. Белгечләр белән бердәмлектә яңа килгән балаларның бакчага ияләшүгә, күнегүгә шартлар булдыру.
8. Белгечләрне матур әдәбият, дидактик уеннар, рәсемнәр белән тәэтмин итә.
9. Белгечләрнең сорауларына җавап бирә, үтенечләрен канәгатьләндерә, проблемалы ситуацияләрне хэл итүдә ярдәм күрсәтә.
10. Белгечләргә татар телен үзләштерүдә ярдәм итә, консультация үткәрә, киңәшләр бирә.

## 3.3. Татар теле тәрбиячесенең тәрбиячеләр белән бердәм эшчәнлеге

1. Тәрбиячеләр белән бердәм эшчәнлектә балаларның индивидуаль узәнчелекләрен туры китереп, әдәби-музыкаль репертуар сайлауга ярдәм итә.
2. Тәрбиячеләргә милли бәйрәм кичәләрен әзерләүдә һәм үткәрүдә булыша.
3. Тәрбиячеләр белән бердәмлектә татар халыкның милли уеннарын, җырларын балаларга җиткерү өстендә эш алып бара.
4. Тәрбиячеләр белән бердәмлектә төркемнәрдә татар теле почмакларын булдыруда ярдәм итә.
5. Тәрбиячеләр белән бердәмлектә яңа килгән балаларның татар телен үзләштерүгә, яратуга шартлар булдыру.
7. Тәрбиячеләрне матур әдәбият, дидактик уеннар, рәсемнәр белән тәэтмин итә.
8. Тәрбиячеләрнең сорауларына җавап бирә, үтенечләрен канәгатьләндерә, проблемалы ситуацияләрне хэл итүдә ярдәм күрсәтә.
9. Тәрбиячеләрнең  татар телен үзләштерүдә ярдәм итә, консультация үткәрә, киңәшләр бирә.
10. Төркемнәрдә УМК почмагындагы дидактик уеннарының картотекасын булдыру һәм аларны яңарту буенча эш алып бара.
11. Тәрбиячеләр белән шогыйльләр үткәрә,  диагностика үткәреп, алар нәтиҗәләре буенча коррекцион эш алып бара.

## *3.4 Программаны методика белән тәэтмин итү*


1. Әдәп – матур гадәт: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик кулланма / Төз.: З.М.Зарипова.- Яр Чаллы, 2009

2. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / М.А.Васильева, В.В.Гербова, Т.С.Комарова ред.; 4 нче русча басмадан К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, З.Г.Ибраһимова, Г.Р.Гыйләҗетдинова, Ф.Җ.Җәләлетдинова тәрҗ.- Казан: Мәгариф, 2006.- 286 б.
3. Бал бабай: балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен кулланма / Төз.: З.М.Зарипова, И.М.Хәмитов.- Яр Чаллы, 2000.- 167 б.
4. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз.: К.В.Закирова, Р.А.Борһанова.- Казан: Хәтер, 2000.- 192 б.
5. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / Төз.: К.В.Закирова.- Казан: РИЦ, 2011.- 560 б.
6. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр,
7. башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик кулланма / Төз.: З.М.Зарипова, иҗади төркем.- Яр Чаллы, 2000.- 70 б.
8. Гөлбакча (балалар бакчалары өчен хрестоматия): балалар бак чаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма / Төз.: Ф.Ю.Юсупов, З.Ф.Камалова, Р.А.Борһанова.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.- 254 б.
9. Закирова К.В., Гаффарова С.М. Әткәм-әнкәмнең теле: балалар бакчасы тәрбиячеләренә кулланма.- Казан: Мәгариф, 1997.- 152 б.
10. Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез (балалар бакчасында уеннар): балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2005.- 175 б.
11. Иң матур сүз: ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия / Төз.: К.В.Закирова.- Казан: Мәгариф, 2000.- 335 б.
12. Кашапова М.Ф. Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: монография.- Казан: РИЦ «Школа», 2009.- 160 б.
13. Кашапова М.Ф. Иң гүзәл тел – туган тел: балалар бакчасында сөйләм телен үстерү буенча методик кулланма.- Казан: РИЦ «Школа», 2009.- 200 б.
14. Кашапова М.Ф. Иң татлы тел – туган тел: балалар бакчалары өчен сөйләм үстерү буенча методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2004.- 446 б.
15. Кашапова М.Ф. Уйныйк әле, балалар: 1 нче китап.- Казан: РИЦ, 2011.- 216 б.

16.Программа по обучению детей русскому языку / Сост.: З.М.Зарипова, Л.З.Галиуллина, Д.Г.Мансурова,
17.С.Г.Хисамутдинова, А.М.Лотфуллина, Г.Х.Сулейманова, Р.М.Алексеева, Е.И.Муллахметова, Л.З.Касаева.- Набережные Челны, 2004.- 111 с
18.Юлда йөрсәң, уяу бул: балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма / Төз.: .Л.Гыйниятуллина. - Яр Чаллы, 2008.- 64 б.
19.Уйный-уйный белем алабыз: Башлангыч сыйныф һәм татар теле укытучыларына, тәрбиячеләргә ярдәмлек.- Казан: КПК,2010,- 100б.
20.Закирова К.В., Мортазина Л.Р. Әй уйныйбыз,уйныйбыз... Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.- Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.- 224б.
21.Закирова К.В. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик кулланма/ К.В. Закирова, Р.Ә. Кадыйрова, Г.М. Сафиуллина.- Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.- 424б.
22.Зарипова З.М. Непосредственно образователҗная деятелҗностҗ в детском саду: методическое пособие для воспитателей детских садов= Балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен методик кулланма/ З.М. Зарипова, А.Х. Габдрахимова, А.Т. Миникаева.- Казань: Первая полиграфическая компания, 2013- 240с.
23.Кашапова М.Ф. Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: монография.- Казан: ТГДПУ, 2009.- 120б.
24.Закирова К.В., Мортазина Л.Р. Балачак- уйнап-көлеп үсәр чак: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма/К.В. Закирова, Л.М. Мортазина.-Казан: Редакционно-издательский центр, 2012.- 192б.
25.Туган телдә сөйләшәбез: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек/Төз.: З.М. Зарипова, Л.Н. Вәҗиева, Р.С. Зөфәрова һ.б.- Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2016.- 299б.